Тукай муниципаль районы Кнэз авыл җирлеге
Чыршылы авылында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» ноябрь, 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кнэз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнэз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнэз авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 декабрендәге 12/4 номерлы карары нигезендә Чыршылы авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Кнэз авыл җирлеге Чыршылы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мен) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм **I, II** төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чыршылы авылында бистә эчендәге юлларны асфальт һәм вак таш белән ремонтлау һәм реконструкцияләү);**

**-урамнарны яктырту җайланмасы (Чыршылы авылында яктырткычлар сатып алу, урамнарны яктыртуны монтажлау һәм урнаштыру);**

**- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Чыршылы авылында суүткәргечне ремонтлау).**

2.Тукай муниципаль районы Кнэз авыл җирлеге Чыршылы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Кнэз авыл җирлеге Чыршылы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Кнэз авыл җирлеге башлыгы И.М.Вилданов